МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.12.2016 г.Казань № 248/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

"Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыелу турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы "и" пунктчасы, Россия Федерациясе Президентының "Коррупциягә каршы көрәшнең кайбер мәсьәләләре турында" 2015 елның 8 мартындагы 120 номерлы Указының 2 пункты, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" 2015 елның 8 июнендәге ПУ-542 номерлы Указы нигезендә

боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә,

Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
2016 елның 28 декабрендәге 248/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары**
**исемлеге**

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында” 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрында вазыйфаларның югары төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

Татарстан Республикасы министрының беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы министры урынбасары.